**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты
карары**

**№1792
04.04.2022**

«Конкурентлы сатып алуларны үстерү агентлыгы» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пунктчасы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. «Конкурентлы сатып алуларны үстерү агентлыгы» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2022 елның 4 апрелендәге
1792 номерлы карарына
кушымта

«Конкурентлы сатып алуларны үстерү агентлыгы»
муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Бәя сумнарда |
|---|---|---|
| 1. | Сатып алулар өлкәсендәге законнар буенча юридик консультация бирү | 1989,00 |
| 2. | Документлар пакеты әзерләү һәм ЭТПда аккредитация алу буенча техник ярдәм күрсәтү | 4 182,00 |
| 3. | Сатулар турында мәгълүмат мониторингы (эшчәнлек өлкәсе буенча тендерлар сайлап алу) | 3 356,00 |
| 4. | Электрон аукцион буенча ярдәм күрсәтү (тәэмин итүчеләр өчен) | 4 798,00 |
| 5. | Электрон сәүдә мәйданчыкларында тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү процедурасында ярдәм күрсәтү | 1 303,00 |
| 6. | Сатуларда катнашуга заявка әзерләү (тәэмин итүчеләр өчен) | 4 984,00 |
| 7. | ТР Федераль монополиягә каршы хезмәт идарәсенә, судларга гариза әзерләү | 5 012,00 |
| 8. | ТР Федераль монополиягә каршы хезмәт идарәсендә, судларда мәнфәгатьләрне яклау | 15 272,00 |
| 9. | Файдалану хокукларын реализацияләү, дәүләт яки муниципаль мөлкәтне арендалау, сату шартнамәсе төзү хокукына электрон аукцион үткәрү | 4 938,00 |
| 10. | Аукцион процедурасы үткәрү | 812,00 |
| 11. | Файдалану хокукларын реализацияләү, дәүләт яки муниципаль мөлкәтне арендалау, сату шартнамәсе төзү хокукына ачык аукцион үткәрү (1 лот) | 8 540,00 |
| 12. | Файдалану хокукларын реализацияләү, дәүләт яки муниципаль мөлкәтне арендалау, сату шартнамәсе төзү хокукына ачык аукцион үткәрү (2-6 лотлар) | 11 969,00 |
| 13. | Файдалану хокукларын реализацияләү, дәүләт яки муниципаль мөлкәтне арендалау, сату, шартнамәсе төзү хокукына ачык аукцион үткәрү (6 дан башлап һәм аннан күбрәк лот) | 14 611,00 |
| 14. | Электрон формада конкурс яки аукцион үткәрү юлы белән тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү | 11 076,00 |
| 15. | Сатып алу эшчәнлеге буенча юридик ярдәм (44-ФЗ номерлы, 223-ФЗ номерлы Федераль закон буенча) | 7 123,00 |
| 16. | Консультация семинарлары үткәрү (бер академия сәгатенең бәясе) | 688,00 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева